РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Кукмара ш.

**29.12.2020** **№ 723**

«2021– 2023 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында терроristлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасы турында

«Терроristлыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Терроristлыкка каршы тору чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге Россия Федерациясе Президентының 116 номерлы Указы нигезендә, Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2018 елның 28 декабрендәге Комплекслы планына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында терроristлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын (алга таба – Программа) 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә һәм муниципаль район Башкарма комитеты бүлекләре башлыкларына Программаның тиешле пунктларын үтәүне тәэмин итәргә һәм Кукмара муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия секретаренә аларның үтәлеше турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга тәкъдим итәргә.

3. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына чираттагы финанс елына бюджет формалаштырганда, Программаны тормышка ашыру срокларын исәпкә алып, Программа нигезендә чараларны финанслауга ассигнованиеләр кертергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә (http://kukmor.tatarstan.ru)Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның ___ ноябрендәге ____
номерлы карарына кушымта

**«2021– 2023 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – Программа)**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021– 2023 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Террористлыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террористлыкка каршы тору чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге Россия Федерациясе Президентының 116 номерлы Указы, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2018 елның 28 декабрендәге «2019 – 2023 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплексы планы» |
| Программаның дәүләт заказчысы | Кукмара муниципаль районы Советы |
| Программаның координаторы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп башкаручылары | - Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты<br>- Муниципаль район Башкарма комитетының Мәгариф, Мәдәният, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәләре;<br>- муниципаль районның җирле үзидарә органнары;<br>- муниципаль районда террорчылыкка каршы комиссия;<br>- ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районындагы бүлеге (килешү буенча);<br>- «Татмедиа» АҖ филиалы;<br>- төрле милек формасындагы учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр;<br>- иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр. |
| Программаның максаты: | Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, аларның экстремистлыкка һәм терроистлыкка каршы тору, Кукмара муниципаль районы территориясендә аларның күренешен профилактикалау һәм кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү |
| Программаның бурычлары | Терроризм идеологиясе йогынтысына дучар булган, шулай ук аның йогынтысына эләккән затлар белән профилактик эш алып бару өчен шартлар булдыру.<br>Кукмара муниципаль районы халкында терроистлыкка каршы аң формалаштыру.<br>Муниципаль мәгариф, мәдәният, спорт объектлары һәм гражданнар күпләп була торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итү. |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары<br><br>Программаның еллар буенча бүленгән финанслау күләме</td><td>2021 – 2023 еллар<br><br>Кукмара муниципаль районының җирле бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 10602,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br><table><tr><td>еллар</td><td>Җирле бюджет акчалары (мең сум)</td></tr><tr><td>2021</td><td>3400,0</td></tr><tr><td>2022</td><td>3532,0</td></tr><tr><td>2023</td><td>3670,0</td></tr><tr><td>Барлыгы</td><td>10602,0</td></tr></table></td></tr>
<tr><td>Финанслау чыганаклары</td><td>Әлеге Программаны тормышка ашыру белән бәйле чараларны финанслау тиешле финанс елына Кукмара муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр кысаларында гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыру өчен тотыла торган акча күләме район бюджеты мөмкинлекләреннән, Кукмара муниципаль районы территориясендә инфляция процессларыннан һәм икътисади вәзгыятьтән чыгып ачыкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин.</td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре</td><td>Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- терроризм һәм экстремистлыкны профилактикалауның дәүләт системасының нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- районда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче Кукмара муниципаль районы халкы саны арту;<br>- террорчылык һәм экстремистлык күренешләренең барлык фактларына түземсезлек формалаштыру;<br>- террористлыкны һәм экстремистлыкны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итү;<br>- террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны алга таба үстерү;<br>- ксенофобия, милли һәм раса түземсезлеге, этник дискриминациягә каршы тору күренешләрен профилактикалау буенча җирле үзидарә органнарының эш формаларын һәм методларын камилләштерү.<br>- район территориясендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча территориаль дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту;<br>- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен күтәрү;<br>- экстремистлыкка, этник һәм дини түземсезлеккә каршы торуның хокукый, оештыру һәм идеологик механизмнарының нәтиҗәле системасын булдыру.</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тоту</td><td>Әлеге программаның тормышка ашырылуын Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе контрольдә тота</td></tr>
</table>

## I. Кереш.
## Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы

«2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын (алга таба – Программа) эшләү һәм кабул итү террористлыкка һәм экстремистлыкка каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнарының тырышлыкларын алга таба да берләштерү, террористлыкка һәм экстремистлыкка каршы тору буенча нәтиҗәле чаралар әзерләү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә аларның эшчәнлеген координацияләү дәрәҗәсен күтәрү һәм даими хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру, барлыкка килгән террорчылык янауларына көчләрнең һәм чараларның ситуацион реакция әзерлеген тәэмин итү, аларның күренешләрен минимальләштерү һәм бетерү, террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалауга комплекслы якын килүне гамәлгә ашыру, терроризм һәм экстремизм күренешләре барлыкка килүгә китерә торган шартларның һәм факторларның тискәре йогынтысын ачыклау һәм киметү зарурлыгына бәйле.

Террористлыкка каршы торуның халыкара һәм илебез тәҗрибәсе көч методларының террорлык акты кылуның конкрет куркынычын гына локальләштерергә сәләтле булуын күрсәтә. Шул ук вакытта терроризм куркынычын радикаль киметү өчен, аның нигезен терроризм идеологиясе, аны рухландыручылар һәм йөртүчеләр, шулай ук тарату каналларын тәшкил итә торган инфраструктурасын яңарту системасын җимерергә кирәк.

Сирия һәм Гыйрак территориясендә террорчылык оешмалары әгъзаларының эшчәнлеге, Татарстан Республикасында халыкара террорчылык һәм экстремистик оешмалар әгъзалары һәм ярдәмчеләренең булуы тышкы куркыныч тудыручы фактор булып тора.

Район территориясендә террористлыкка каршы тору өлкәсендәге хәлгә йогынты ясый торган төп эчке куркыныч тудыручы факторлар булып түбәндәгеләр тора:

- эш эзләү һәм эшкә урнашу белән бәйле якын чит илләрдән миграция агымнары;
- икътисадта кризис күренешләре (халыкның тормыш дәрәҗәсе кимү һәм эшсезлекнең үсүе), шул исәптән озак вакытлы карантин кертү белән дә бәйле һәм социаль каршылыкларны тирәнәйтә торган;
- район территориясендә экстремистлыкка каршы тору линиясе буенча оператив-профилактик исәптә торучы теркәлгән затларның һәм аларның якын туганнарының (хатыннары, ирләре, балалары һәм фикердәшләре) булуы;
- деструктив берләшмәләрнең Интернет челтәре аша яшьләр мохитенә тискәре йогынтысы;
- радикаль теологик өйрәнүләр тарафдарларының дини мохиткә тискәре йогынты;
- террорчылык көче куллану ихтималы булган объектларны, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт һәм кешеләр күпләп була торган урыннарны террорчылыкка каршы яклауда булган җитешсезлекләр.

Кукмара районы күп милләтле, биредә православие һәм ислам диненең әйдәп баручы ике төп конфессиясе, шулай ук башка халыклар һәм конфессияләр вәкилләре тату һәм аңлашып яши.

2020 ел башына районда халык саны 50840 кеше тәшкил иткән, шуларның 78,6%ы – татарлар, 14,0%ы – удмуртлар, руслар – 5,3%, 1,5%ы – марилар һәм 0,6%ы – башка милләт халыклары (башкортлар, чуашлар, мордва, үзбәкләр, әзербайҗан, әрмән, вьетнамлылар, кореялеләр һәм башкалар).

2020 елда иҗтимагый-сәяси һәм оператив хәл үзгәреш кичерде, әмма тулаем алганда, чагыштырмача тотрыклы кала һәм контрольдә тотыла.

Кукмара муниципаль районында террористлыкка һәм экстремистлыкка каршы тору өлкәсендәге оператив хәл мониторингы күрсәткәнчә, оператив хәл, 2020 елның 30 октябрендә террорчылык акты кылырга омтылуның теркәлгән очрагы булганлыктан, киеренке саклана.

Эш Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, районның террорчылыкка каршы комиссиясе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге, җирле үзидарә органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла, районда экстремизм, этник һәм дини дискриминация күренешләре буенча оператив хәлләр мониторингы даими рәвештә алып барыла. Җирле үзидарә органнары тарафыннан район җирлекләрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышына аерым мониторинг алып барыла.

Экстремизм – уртак куркыныч, һәм аның идеологиясен дәүләт һәм муниципаль институтларның, фәнни һәм мәгариф даирәләренең, бизнес-бергәлекләрнең, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм гражданлык җәмгыяте структураларының уртак координацияләнгән каршы көрәше белән генә җиңеп була. Экстремистлык үзенең барлык чагылышларында да гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә, җәмәгать куркынычсызлыгын, дәүләт бөтенлеген һәм Россиянең халыкара абруен какшата, конституцион строй нигезләренә, милләтара һәм конфессияара тынычлыкка реаль куркыныч тудыра.

Экстремистлык идеологиясен тарату террористик оешмалар сафына яңа әгъзалар килүен һәм ресурс ярдәме белән тәэмин итә. Террорчылык куркынычын киметү бурычы турыдан-туры экстремистлык идеологиясенең актив таралуына каршы тору белән бәйле. Аның йогынтысының төп мишене булып, гражданнар тәңгәллеге һәм хокук аңы формалашу ягыннан иң пластик һәм тотрыксыз мохит буларак, яшүсмерләр һәм яшьләр тора.

Кукмара муниципаль районында милләтара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу буенча уңай тәҗрибә тупланган, башлангыч стадиядә экстремизм хәвеф-хәтәрләрен бетерү, халыкның толерантлыгын арттыру һәм этносоциаль һәм дини каршылыкларны җиңү буенча актив эш алып барыла.

Экстремистлыкка һәм террористлыкка, хокук бозулар кылуга, сәбәпләрне һәм шартларны кисәтүгә, ачыклауга, бетерүгә юнәлдерелгән чараларга системалы якын килү муниципаль районда социаль-икътисадый хәлне яхшыртуның иң мөһим шартларыннан берсе булып тора. Мондый алымны гамәлгә ашыру өчен, террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча халыкның ирекле формированиеләре эшчәнлеге өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирә торган һәм муниципаль районның, шулай ук хокук бозуларны профилактикалау

өлкәсендә башка субъектларның җирле үзидарә потенциалыннан максималь файдалануны күздә тоткан муниципаль программаны кабул итү зарур.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык документ булып тора.

**2. Программаның төп максаты һәм бурычлары**

Программаның максаты – экстремистлык һәм террористлыкка каршы тору нигезендә Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү.

Программаның максатына ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

Террористлык идеологиясе йогынтысына дучар булган, шулай ук аның йогынтысына эләккән затлар белән профилактик эш алып бару өчен шартлар булдыру.

Кукмара муниципаль районы халкында террористлыкка каршы аң формалаштыру.

Муниципаль мәгариф, мәдәният, спорт объектлары һәм гражданнар күпләп була торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итү.

Төп максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада каралган чараларны финанслау күләме кушымтада күрсәтелгән.

**3. Программаны тормышка ашыру механизмы**

Программаның үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольне ел саен Программаның максатчан күрсәткечләрен һәм чараларына чыгымнарны, аны тормышка ашыру механизмын һәм чараларны үтәү өчен җаваплы башкаручыларның составын, программаны үтәү барышы турында белешмәләрне ачыклаучы Программаның башкаручы-координаторы гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә торган карарлар (беркетмәләр) тиешле профилактика субъектлары тарафыннан үтәлә. Вәкаләтле орган каршында терроризм һәм экстремистлыкны профилактикалауның аерым юнәлешләре буенча яисә бу өлкәдә конкрет проблеманы хәл итү өчен эшче комиссияләр (төркемнәр) оештырылырга мөмкин. Профилактика субъектларында штаттан тыш нигездә вәкаләтле орган белән хезмәттәшлек итү һәм программа чараларының үтәлешен координацияләү буенча, алар компетенциясе кысаларында кабул ителә торган карарларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган эш төркемнәре төзелергә мөмкин. Вәкаләтле орган эшендә катнашу өчен аларның ризалыгы белән суд органнары һәм прокуратура органнары вәкилләре чакырыла ала.

Дәүләт заказчысы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- терроризм һәм экстремистлыкны профилактикалау торышын анализлау һәм алга таба профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләү;
- муниципаль район Башлыгына, район Башкарма комитеты җитәкчесенә профилактик эшчәнлекнең торышы турында мәгълүмат бирү, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр кертү;
- террористлыкны һәм экстремистлыкны кисәтү, аларны кылуга ярдәм итүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү мәсьәләләре буенча профилактика субъектлары җитәкчеләрен тыңлауны оештыру;
- түбәндәгеләр буенча профилактика субъектлары эшчәнлеген координацияләү:

а) террористлыкны һәм экстремистлыкны кисәтү, профилактиканы камилләштерү чараларын эшләү;

б) террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау өлкәсендә норматив хокукый актлар әзерләү;

в) халык, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне ныгыту һәм тыгыз хезмәттәшлекне җайга салу.

Программаны тормышка ашыруның өстенлекле юнәлешләре булып тора:

- оештыру чаралары;
- терроризмны профилактикалау буенча чаралар;
- милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту буенча чаралар;
- балалар һәм яшьләр арасында экстремистлыкны профилактикалау буенча чаралар;
- Программа чараларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү.

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәү, аны тормышка ашыру өчен бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалану өчен, министрлыкларның, ведомстволарның территориаль органнары җитәкчеләре, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәү йөзеннән гамәлгә ашырыла. Кукмара муниципаль районы Советы һәм Кукмара муниципаль районында Террорчылыкка каршы комиссия утырышларында, программаны башкаручыларның җитәкчеләрен тыңлап, программа чараларының үтәлешен һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген даими рәвештә карау планлаштырыла.

Җаваплы башкаручыларга Кукмара муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясенә Программа чараларының үтәлеше турында хәбәр итәргә.

**4. Программаның ресурс белән тәэмин ителешен нигезләү.**

Программа чараларын тормышка ашыруга финанс чыгымнары аның гамәлдә булу чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты акчаларыннан агымдагы финанслау чикләрендә була.

Программаны тормышка ашыру өчен тотыла торган акча күләме район бюджеты мөмкинлекләреннән, Кукмара муниципаль районы территориясендә инфляция процессларыннан һәм икътисади вәзгыятьтән чыгып ачыкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

**5. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү.**

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- район территориясендә террорчылык актлары кылу ихтималын минимальләштерү;
- терроризм һәм экстремистлыкны профилактикалауның дәүләт системасының нәтиҗәлелеген арттыру;
- террористлыкны һәм экстремистлыкны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итү;
- терроризм һәм экстремистлыкны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны алга таба үстерү;
- район территориясендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча территориаль дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту;
- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен күтәрү.

Программаны тормышка ашыру Кукмара муниципаль районының күпмилләтле халкының рухи бердәмлеген һәм гомумхалык аңын ныгыту мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнарының, гражданлык һәм фәнни-эксперт бергәлеге институтларының көчләрен берләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

«2021 – 2023 елларга Кукмара муниципаль районында террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» Программасына кушымта (Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 28 декабрендәге ПР–2665 номерлы Указы белән расланган 2019 – 2023 елларга Россия Федерациясендә террористлык идеологиясенә каршы торуның Комплекслы планыннан чараларны да кертеп)

**«2021 – 2023 ЕЛЛАРГА КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ТЕРРОРЧЫЛЫКНЫ ҺӘМ ЭКСТРЕМИСТЛЫКНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ» ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларның үтәлү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Максаты: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын, аларның экстремистлыкка һәм террористлыкка каршы тору, Кукмара муниципаль районы территориясендә аларның көренешен профилактикалау һәм кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү** | | | | | | | | | | |
| | | | | 2020 (база елы | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| **1 нче бурыч Террористлык идеологиясе йогынтысына дучар булган, шулай ук аның йогынтысына бирелгән затлар белән профилактик эш алып бару өчен шартлар булдыру** | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1.1. Экстремистлык характерындагы мәгълүматны ачыклау һәм террорчылык эшчәнлеген башкаруга өндәүләрне ачыклауга юнәлдерелгән «Интернет» челтәрен мониторинглау буенча эшче төркем эшен тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районында террорга каршы көрәш комиссиясе каршындагы пропаганда төркеме | 2021 – 2023 еллар | Эшче төркемнәрнең утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. Аерым игътибар категориясендәге затлар белән адреслы профилактик чараларда катнашу өчен коммерцияле булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм иҗтимагый активларны стимуллаштыру чараларын гамәлгә ашырырга | Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2021 – 2023 еллар | Иҗтимагый активистларны җәлеп итеп, профилактик эш алып барыла торган аерым игътибар (риск) категориясендәге затлар өлеше | 40 | 50 | 60 | 70 | 10 | 10 | 10 |
| 1.3. Ааерым игътибар категориясендәге затлар белән эшләүдә, хәлне диагностикалауда, психологик һәм психотерапевтик ярдәм күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларны һәм иҗтимагый активистларны әзерләү өчен квалификацияле белгечләрне җәлеп итүне тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2021 – 2023 еллар | Җәлеп ителгән квалификацияле белгечләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 10 | 10 | 10 |
| 1.4. Яшьләр эшләре бүлеге, спорт оешмалары, яшьләр иҗтимагый активистларының аерым игътибар категориясендәге затларның социальләшү характерына ярдәм итү буенча өзлексез чараларны тормышка ашыруда актив катнашуын тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Күрсәтелгән хезмәт төрләре белән колачланган аерым игътибар категориясендәге затлар өлеше | 10 | 15 | 20 | 25 | 10 | 10 | 10 |
| 1.5. **Функциональ** регламент белән беркетелгән белем бирү оешмаларының вазыйфаи затларының аерым игътибар категориясе затлары белән адреслы кисәтү эше алып баруда актив катнашуын тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Аерым игътибар категориясендәге затлар (яки аларның балалары) белем ала торган уку сыйныфлары белән төркемле корректлау чаралары (тренинглар, семинарлар) өлеше | 70 | 80 | 85 | 90 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.6. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык субъектлары белгечләренең аерым игътибар (риск) категориясе гаиләләре белән, шул исәптән торгызу медиациясе техникасын кулланып, профилактик чараларны гамәлгә ашыруда актив катнашуын тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районындагы Террорчылыкка каршы комиссия, балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектлары | 2021 – 2023 еллар | «Аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар яши торган гаиләләрнең гомуми саныннан профилактика чаралары белән колачланган гаиләләр өлеше | 10 | +10 % | +10 % | +10 % | 10 | 12 | 15 |
| 1.7. Адреслы профилактик эштә катнашучы белгечләрнең һөнәри осталыгы буенча тармакара семинарлар үткәрергә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районындагы Террорчылыкка каршы комиссия | 2021 – 2023 еллар | Семинарлар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| 1.8. Яшьләр даирәсендә һәм мәгариф өлкәсендә мәгариф, яшьләр сәясәте, медицина, социаль яклау өлкәсенә социаль педагогларны, психиатрларны җәлеп итү өчен, тиешле белем алуда һәм белгечлек буенча муниципаль берәмлектә эшкә урнашуда мәгълүмати ярдәм күрсәтү өчен һөнәри юнәлеш бирү эше алып барырга | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны | 2021 – 2023 еллар | Әлеге өлкәләрдә белгечләрне комплектлау проценты | 10 | + 10% | + 10% | + 10% | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара районындагы социаль яклау бүлеге ДАССУ «Кукмара РҮХ» | | | | | | | | | |
| 1.9. Аерым игътибар категориясе затларын массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, халык алдында террорчылык идеологиясен кабул итмәүне формалаштыруга һәм традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне үстерүгә юнәлдерелгән чыгышлар ясарга тарту буенча эш алып барырга | Кукмара муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2021 – 2023 еллар | Мондый аңлатмалар белән чыгыш ясаган аерым игътибар (риск) категориясендәге затлар өлеше | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 1.10. системалы хезмәт һәм уку процессына җәлеп ителмәгән яшьләрне, шулай ук формаль булмаган яшьләр оешмалары вәкилләрен иҗтимагый әһәмиятле социаль проектларны һәм программаларны тормышка ашыруга җәлеп итү буенча чаралар оештырырга һәм үткәрергә . | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Максатчан аудиториянең гомуми санынннан җәлеп ителгән яшьләр өлеше | 10 | + 10% | + 10% | + 10% | 10 | 12 | 15 |
| 1.11. Интернет челтәрендәге деструктив берләшмәләрдә муниципаль берәмлек халкының активлыгына мониторинг үткәрүне тәэмин итәргә (катнашучыларны матди кызыксындыру) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, «Форпост үзәге» | 2021 – 2023 еллар | Мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат белешмәләре саны | 12 | 12 | 12 | 12 | 15 | 20 | 30 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | МБУ | | | | | | | | | |
| 1.12. Даими мониторинг оештырырга һәм муниципаль берәмлектә таратыла торган материалларны аларда экстремистлык билгеләре булу-булмауга тикшеренүләр үткәрергә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге | 2021 – 2023 еллар | үткәрелгән тикшеренүләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 20 | 20 | 20 |
| 1.13. Дини оешмалар җитәкчелеге белән берлектә Россиянең алдынгы технология уку йортларына (Болгар ислам академиясе) Татарстан Республикасы өчен традицион ислам формаларын тотучы дини лидерларны әзерләү өчен кандидатларны сайлап алу һәм җибәрү процедурасын оештырырга | -<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 – 2023 еллар | җибәрелгән кандидатлар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| **2 нче бурыч Кукмара муниципаль районы халкында террористлыкка каршы аң формалаштыру** | | | | | | | | | | |
| 2.1. Мәгълүмати-пропаганда төркеме эшчәнлеген тәэмин итәргә (катнашучыларны матди кызыксындыру) | Кукмара муниципаль районында террорга каршы көрәш комиссиясе каршындагы пропаганда төркеме | 2021 – 2023 еллар | Эшче төркемнәрнең утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 10 | 15 | 20 |
| 2.2. Террористлыкка каршы юнәлештәге күрсәтмә агитация продукциясен (стикерлар, брошюралар, плакатлар) эшләргә, әзерләргә һәм таратырга (урнаштырырга) | Мәгълүмати-пропаганда төркеме, авыл җирлекләре башлыклары | 2021 – 2023 еллар | Продукция берәмлекләре саны | 10 | 10 | 10 | 10 | 20 | 25 | 30 |
| 2.3. Халык белән мәгълүмати аңлату эшләре алып бару өчен, аларга матди стимул бирүне карап, квалификацияле лектор-пропагандистларны җәлеп итүне тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 – 2023 еллар | җәлеп ителгән лекторлар тарафыннан үткәрелгән лекцияләр/чыгышлар | 2 | 2 | 2 | 2 | 10 | 12 | 15 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | саны | | | | | | | |
| 2.4. Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен лектор-пропагандистларның муниципаль активын әзерләүне тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары | 2021 – 2023 еллар | халкы арасыннан укытылган лекторла саны муниципаль берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | 10 | 12 | 15 |
| 2.5. Террористлыкка каршы көрәштә бердәмлек көненә багышланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары үткәрергә (3 сентябрь) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, «Хезмәт даны» район газетасы | 2021 – 2023 еллар | чараларның саны | | | | | 10 | 12 | 15 |
| 2.6. «Экстремистлыкка – юк» ункөнлеген үткәрергә (4 – 14 сентябрь) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, «Хезмәт даны» район газетасы, авыл җирлекләре башлыклары, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге, дини, | 2021 – 2023 еллар | чараларның саны (ункөнлек планы буенча) | | | | | 10 | 12 | 15 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | иҗтимагый оешмалар | | | | | | | | | |
| 2.7. Муниципаль районда уяулыкны саклау, террористлыкны һәм экстремистлыкны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннары үткәрергә | Авыл җирлекләре башлыклары | 2021 – 2023 еллар | авыл җирлекләрендә җыеннар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| 2.8. Террорчылыкка каршы эчтәлекле мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны, социаль челтәрләрнең муниципаль сегментында, Интернет челтәренең башка мәгълүмат ресурсларында эшләүне (сайлап алуны) һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Хезмәт даны» район газетасы | 2021 – 2023 еллар | урнаштырылган материаллар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 10 | 10 | 10 |
| 2.9. Массакүләм мәгълүмат чараларында террористлыкка каршы тору эшендә гражданнарны берләштерүгә юнәлдерелгән рәсми дини конфессияләр (православие, ислам) вәкилләренең тематик вәгазьләрен бастырып чыгаруны оештырырга | Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты, «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Хезмәт даны» район газетасы, дини һәм иҗтимагый оешмалар (килешү буенча ) | 2021 – 2023 еллар | мәкаләләр саны | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| 2.10. Авыл клубларында һәм мәдәният йортларында террористлыкка һәм экстремистлыкка каршы юнәлештәге документаль һәм нәфис фильмнарны даими күрсәтүне оештырырга, соңыннан аудитория белән фикер алышу оештырырга | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2021 – 2023 еллар | күрсәтүләр саны | 10 | 10 | 10 | 10 | - | - | - |
| 2.11. Яшьләр арасында кейс чемпионатлар, квестлар, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, фестивальләр, конкурслар, акцияләр оештырырга | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәдәният бүлеге | 2021 – 2023 еллар | чараларның саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 |
| 2.12. Террористлыкка һәм экстремистлыкка | Яшьләр эшләре һәм | 2021 – 2023 | бәйгегә гаризалар | 5 | 5 | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| каршы тору өлкәсендә иң яхшы проектка (иҗади эш) конкурс үткәрергә | спорт бүлеге | еллар | саны | | | | | | | |
| 2.13. Коммуникатив күнекмәләрне арттыруга, дуслык, милләтара һәм диниара татулык идеяләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән тематик түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, конкурслар, ата-аналар җыелышлары, сыйныф сәгатьләре, акцияләр, тренинглар оештырырга | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2021 – 2023 еллар | чараларның саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 |
| 2.14. «Ата-аналар университеты» форматында үзара аңлашу, милләтара бердәмлек, балаларга медиа-куркынычсызлык мәсьәләләрендә аларның белем дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән дәресләр үткәрүне оештырырга | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2021 – 2023 еллар | Гомуми гаиләләр санында профилактик дәресләрдә катнашкан ата-аналарның өлеше.% | 50 | 55 | 60 | 65 | - | - | - |
| **3 нче бурыч Муниципаль мәгариф, мәдәният һәм спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү** | | | | | | | | | | |
| 3.1 Мәдәният, мәгариф һәм спорт объектларында террорчылык янавы һәм башка гадәттән тыш хәлләр турында хәвеф сигнализациясе системаларын үстерү һәм техник хезмәт күрсәтү буенча чаралар үткәрергә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 – 2023 еллар | җиһазландырылган объектларның өлеше, процент | 45 | 50 | 60 | 70 | 3195,0 | 3300,0 | 3400,0 |
| **Барлыгы суммар чыгымнар, мең сум** | | | | | | | | 3400,0 | 3532,0 | 3670,0 |